“Укытучы булып туарга кирәк”, - ди халык. Бу сүзләрдә хаклык бардыр шул. Күпме түземлек, сабырлык, тәртип, җыйнак-лык, вакытны дорес бүлә белү һәм тагын бик күп сыйфатларга ия булу кирәк. Балаларны ярату, гомерен буе аларга үрнәк булу, һәм дә алар белән дорес аралашу – күпме коч таләп итә бу һонәр кешесеннән. Күп эзләнү, осталыгынны, белеменне арттыру да укытучы очен бик әһәмиятле.

Ин беренче мәктәп бусагасын атлап кергән коннән алып, зур тормышка озатып, сонгы кынгырау чынлаган конгә кадәр, бала белән һәрчак янәшәдә анын укытучысы атлый. Ул аны белем доньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт һәм ижат шатлыгын тоярга ойрәтә, фикерләү сәләтен үстерә, доньяга карашын формалаштыра, анардан шәхес тәрбияләүгә ботен кочен бирә. Укытучы - ул җәмгыятьнен ин хормәтле һонәр иясе. Ил карты да ана, башын иеп, “Могаллим”, дип, зурлап эндәшә...

Укытучы хезмәте авыр да, жаваплы да, кызыклы да, дидем. Ул зур сабырлык, түземлек, күпкырлы белем, зыялылык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган һонәргә чиксез бирелгәнлек таләп итә. Галим дә, тозүче дә, шагыйрь дә, табиб та укытучыдан башлана. Һәркем укытучысын йорәк түрендә йортә, ин жылы хисләр белән искә ала. Һәркем үзенен тәүге тапкыр мәктәпкә аяк басуын, шаян классташларын, ягымлы, таләпчән укытучыларын онытмыйдыр. Шундый башлангыч сыйныфлар укытучысы булып ярты гасырга якын хезмәт иткән хормәтле Роза Абдулла кызы Алимова турында югарыда әйтелгән сүзләр туры килә. Анын педагогик стажы бер Ләмберә районы Аксен урта мәктәбендә үтә. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын узган балаларнын нәни кулларыннан тотып, тыйнак һәм һәръяклап үрнәк морзалар кавымыннан булган Роза Абдулла кызы, әниләрдәй күнел жылысын биреп, укырга, язарга ойрәтте. Кирәк чакта таләпчән дә була белде ул. Укучыларынын кадерле укытучысы, хезмәттәшләренен кинәшчесе, ярдәмчесе булды укыту елларында. Тәүге коннән үк укучыларын үзенә гашыйк иттерә белде, игътибарлы, ихтирамлы, кече күнелле булу серләренә тошендерде, сыйныфтагы барлык балаларны бергә туплады, тәртипле, акыллы, әхлаклы, кешеләргә ярдәмчел булырга ойрәтте. Анын укучылары тормышта үз урыннарын табып, профессия алдынгылары булдылар. Укытучы очен бу зур уныш. Профессиясендә хормәтле булуына күпторле бүләкләре дә шахит.

Тагы кеше хезмәте белән табигатьне үзгәртә дип әйтәләр. Ә укытучы хезмәте Кешенен үзен формалаштыруы белән кыйммәтле һәм гүзәл. Чынлап та, беренче укытучы ул

һәркемнен кунелендә, якты истәлек булып, гомер буе саклана. Еллар утсә дә, без аны хормәт белән искә алабыз.

Хормәтле Роза Абдулла кызы Алимованын 24нче август конне 75 яшьлек бәйрәме. Аны кайнар котлап балалары Рушания һәм Ринат гаиләләре белән, кунпсанлы туганнары, коллегалары һәм укучылары изге теләкләр телиләр.

Кадерлебез!

75 тулса тулсын, кунелен картаймасын. Йорәктәге дәртен белән мәнге яшь булып кал син. Унышлар юлдаш булсын барасы юлларында. Тынычлык, иминлек булсын алдагы елларында. Авыруны белми яшә, бул син гел уз кочендә. Сине исән-имин кupu бәхет безнен очен дә. Мен-мен рәхмәт барысы очен дә!